КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1202

«Татарстан Республикасында диагнозны хәбәр итү беркетмәсе» юнәлеше буенча «Гомер буе озата бару» программасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара эшче төркем составын раслау турында

Балада инвалид патологиясен яисә аның үсеш куркынычын (шул исәптән ана карынында) ачыклаганда яисә билгеләгәндә балалардан баш тартуны (социаль ятимлекне) профилактикалау, Татарстан Республикасында «Диагнозны хәбәр итү беркетмәсе» юнәлеше буенча «Гомер буе озата бару» программасын гамәлгә кертү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында диагнозны хәбәр итү беркетмәсе» юнәлеше буенча «Гомер буе озата бару» программасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара эшче төркем составын расларга.

2. Эшче төркемгә әлеге карарга кул куйган көннән алып 30 көн эчендә «Татарстан Республикасында диагнозны хәбәр итү беркетмәсе» юнәлеше буенча «Гомер буе озата бару» программасын гамәлгә ашыру буенча «юл картасын» расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 17 апрель, 482 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасында диагнозны хәбәр итү беркетмәсе» юнәлеше буенча «Гомер буе озата бару» программасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эшче төркем рәисе |
| Абашев Әлмир Рәшит улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Игнашина Елена Германовна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсенең балаларга медицина ярдәмен һәм бала тудыру хезмәтен оештыру бүлеге башлыгы, эшче төркемнең җаваплы секретаре |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Васильев Роман Игоревич | Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Волынец Ирина Владимировна | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Газимҗанов Илнур Әсхәт улы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм күрсәтү бүлеге әйдәүче консультанты |
| Закирова Минзалия Заһри кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Зарипов Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| Сенек Светлана Александровна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече-педиатры |

_______________________